**Тесты для II уровня**

1. Татар алфавитында ничә хәреф бар?

А) 39

Б) 38

В) 40

2. Алфавит нәрсә ул?

А) авазлар һәм хәрефләр

Б) язудагы барлык хәрефләр

В) хәрефләрнең кабул ителгән тәртиптә бе-бер артлы урнашуы.

3. Кайсы төркемдә аваз һәм хәреф саны туры килә?

А) ут, яз, көрт, урман

Б) сары, өстәл, бару, тавык

В) куян, тәгам, кәгазь, оя

Г) буяу, мәче, машина, авыр

4. Татар язуы тарихы кайсы төркемдә дөрес күрсәтелгән?

А) рун, гарәп, латин, уйгыр, кирилл

Б) гарәп, латин, кирилл

В) рун, уйгыр, гарәп, латин, кирилл

Г) уйгыр, гарәп, рус, латин

5. Юлдан-юлга күчерүнең дөрес очрагын билгеләгез.

А) аръ-як, адъ-ю-тант, и-ше-гал-ды, я-ңа

Б) аръ-як, адъю-тант, и-ше-гал-ды, я-ңа

В) аръ-як, адъю-тант, ише-гал-ды, яңа

Г) аръяк, адъю-тант, ише-гал-ды, я-ңа

6. Лексика нәрсәне өйрәнә?

А) авазларны һәм хәрефләрне

Б) сүзләрнең ясалышын һәм төрләнешен

В) сүзтезмә һәм җөмләләрне

Г) сүзләр җыелмасын

7. Антонимнар төркемен күрсәтегез.

А) алгарыш, прогресс

Б) азатлык, бәйлелек

В) көч, егәр

Г) авызга су кабу, дәшмәү

8. Омонимнар төркемен күрсәтегез.

А) таба, таба, тиен, тиен

Б) матур, ямьсез, кайгыру, шатлану

В) ашыгу, кабалану, чабу, өтәләнү

Г) кучат, итәй, нәмә, пыцак

9. Рәвеш нинди сорауларга җавап бирә?

А) ничек? кайда? кайчан? күпме?

Б) нинди? кайсы? ничек? кая?

В) күпме? нәрсәне? кая? нишләгәч?

10. Татар телендә ничә килеш бар?

А) 5

Б) 6

В) 8

11. Сыйфатның дәрәҗәсен әйтегез: *Җете кызыл*

А) кимлек

Б) чагыштыру

В) гади

Г) артыклык

12. Кимлек дәрәҗәсе ясаучы кушымчаны билгеләгез.

А) –рак/-рәк

Б) –лы/-ле

В) –сыл/-сел

13. Фигыльләр нәрсә белән төрләнә?

А) заман белән

Б) килеш белән

В) барлык-юклык, заман, зат-сан белән

14. *Кайтуым, каравы, эшләмәүләре* исем фигыльләре нәрсә белән төрләнгән?

А) килеш белән

Б) тартым белән

В) зат-сан белән

15. Җыю саны

А) предметның төгәл исәбен

Б) предметның тәртип буенча санын

В) предметның тигез өлешләргә бүленешен

Г) предметның якынча исәбен

Д) предметлык төшенчәсен белдерә.

16. Кушма сүз

А) ике яки берничә сүз кушылып ясала һәм яңа бер мәгънә белдерә

Б) ике яки берничә сүздән ясала.

17. *Таба, күрә, каршы, кадәр, чаклы, тикле, хәтле* бәйлекләре үзләреннән алда килгән сүзнең нинди килештә булуын таләп итәләр?

А) баш килештә

Б) юнәлеш килешендә

В) чыгыш килешендә

Г) иялек килешендә

18. *Мин, ул, без, алар, син* алмашлыкларының төркемчәсен күрсәтегез

А) күрсәтү

Б) зат

В) билгеләү

Г) сорау

19. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнең килешен билгеләгез:

Мәрьям абыстай, **улына** сыенып, акрын гына елый иде (Ә.Еники)

А) чыгыш килешендә

Б) төшем килешендә

В) юнәлеш килешендә

Г) урын-вакыт килешендә

20. Фразеологик берәмлекләр кергән вариантны күрсәтегез

А) үги ана яфрагы; бүре җиләге; тимер юл; кузы чикләвеге

Б) кара-каршы утыру; каты тавыш белән сөйләү; сукмакны югалту

В) салпы якка салам кыстыру; теш кайрау; йөрәк итен ашау; күз буу

Г) хәрәкәт башлану; кычкырып елау; кунакка килү; җәй үтү.